**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Түбән Кәминкә авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлегенең **Түбән Кәминкә** торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**02 ноябрь 2023 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 01 ноябрендә киләсе мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2024 елда Түбән Кәминкә авыл җирлегенең Түбән Кәминкә торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә I төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операцияләрендә булганнардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

1. **Түбән Кәминкә** торак пунктында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, юл-урам челтәрендәге юл кырыйларын норматив хәлгә китерү, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнары;
2. **Түбән Кәминкә** торак пунктында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, торак пунктларда урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
3. «Кызыл яр» чишмәсен ремонтлау **(Түбән Кәминкә авылы)** чишмә территориясен санитар-саклау зонасын төзекләндерү, койманы ремонтлау һәм буяу, павильон урнаштыру, павильонны тышлау, каты түшәлгән юллар төзү, җир кишәрлекләрен рәсмиләштерү, проект-смета документлары өчен түләү) **Түбән Кәминкә** торак пунктында югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 305 катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 198 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенының 183 катнашучысы тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен 15 катнашучы тавыш бирде.
Бәян ителгәннәр нигезендә халык җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлегенең **Түбән Кәминкә** торак пунктында халык җыены булып узган, халык җыены нәтиҗәләре - чын дип танырга.

2. Киләсе мәсьәлә буенча: «2024 елда Түбән Кәминкә авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә I төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операцияләрендә булганнардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

1. **Түбән Кәминкә** торак пунктында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, юл-урам челтәрендәге юл кырыйларын норматив хәлгә китерү, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнары;

2. **Түбән Кәминкә** торак пунктында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, торак пунктларда урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

3. «Кызыл яр» чишмәсен ремонтлау (**Түбән Кәминкә авылы**) чишмә территориясен санитар-саклау зонасын төзекләндерү, койманы ремонтлау һәм буяу, павильон урнаштыру, павильонны тышлау, каты түшәлгән юллар төзү, җир кишәрлекләрен рәсмиләштерү, проект-смета документлары өчен түләү) **Түбән Кәминкә** торак пунктында югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алу.

4. Халык җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә: **Түбән Кәминкә** авылы, Үзәк урамы, 49, Чирмешән муниципаль районының рәсми интернет сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
ТР Чирмешән муниципаль районы
Түбән Кәминкә авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Халиков